**Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Яңа Шашы авыл җирлеге Советы утырышы**

# КАРАРЫ

6 февраль 2026 ел №12

**Яңа Шашы авыл җирлеге Советының 2019 елның 11 ноябрендәге 110 номерлы карары белән расланган «Яңа Шашы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында " 2025елның 28 ноябрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Яңа Шашы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Яңа Шашы авыл җирлеге Советының 2019 елның 11 ноябрендәге 110 номерлы карары белән расланган «Яңа Шашы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә (10.02.2020 №124, 28.05.2020 №131, 30.10.2020 №6, 06.12.2021 №37, 16.05.2022 №47, 17.08.2022 №51, 27.10.2023 №80, 05.06.2024 №95, 21.04.2025 №117, 19.12.2025 №9 (үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

**1.1. 9 статьяның 6 пунктындагы 2 абзацын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:**

“-Россия Федерациясе Бюджет кодексының 221 статьясы нигезендә билгеләнә торган тәртиптә бюджет сметасын төзи, раслый һәм алып бара;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru. адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгы Сабирҗанов М.С.